Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
Корноухово авыл җирлеге составына керүче Корноухово авылы, Шетнеү Чирмешан
авылы торак пунктларында

**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

2019 елның 31 октябре № 2

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, Татарстан Республикасының "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" Законының 35 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Корноуховоавыл җирлеге составына керүче Корноухово авылы ,Шетнеү Чирмешан, торак пунктларында гражданнар җыены **КАРАР БИРӘ**:

1. 2020 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Корноуховоавыл җирлеге составына керүче Корноухово авылы, Шетнеү Чирмешан торак пунктларында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән, уку йортларына йөреп (көндезге бүлектә) укучы студентлардан һәм 1 төркем инвалидлардан гайре, 500 сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә.

2.Тупланган акчаларны түбәндәгеләргә юнәлтергә: - Корноухово авылында юл ремонты өчен вакланган таш сатып алуга,зиратка кадер юл ремонтлау ;

- транспорт хезмәтләренә түләүгә;

- кышкы чорда Корноухово авылы жирлегендеге юлларны карап торуга һәм чистартуга ;

- су насосы сатып алырга;

-Шетнеү-Чирмешан авылында юл ремонты өчен вакланган таш сатып алуга һәм зиратка кадер юл ремонтлау.

-Шетнеү-Чиремешан авылында зиратны чистарту, сарай ясау;

- Корноухово авылында куркыныч янаган һәм корган агачларны кистерү һәм чистарту.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Корноухово авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Корноухово авылы, Совхоз урамы, 8 йорт, Зюзино авылы, Узек урамы, 6А йорты, Шетнеү Чирмешан авылы, Советлар урамы, 20 йорт ,Наумово авылы, Наумово урамы, 3 йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм

http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Карарны Татарстан Республикасы үзидарәлек хокукый норматив актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Корноуховоавыл җирлеге
башлыгы урынбасары М.Н Хуҗаҗанов